| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2018 Казан ш. № 10-167/кс

«Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – Яр Чаллы ҖЭҮ өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.11.2017 № 10-30/кс карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2019 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2019 елга эчә торган суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының ««Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – Яр Чаллы ҖЭҮ өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга 2018-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 10.11.2017 № 10-30/кс карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.11.2017 № 10-30/кс карарына 1 нче кушымта «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 10-167/кс карары редакциясендә)

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Яр Чаллы ЖЭҮ филиалы өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга 2018-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | | | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Яр Чаллы ЖЭҮ филиалы (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 0,61 | 0,62 | 0,62 | 0,62 | 0,62 | 0,62 | | | | | | |
| 1.1.1 | Технологик яктан үзара бәйләнмәгән үзәкләштерелгән берничә система булуына карап, тарифларны дифференциацияләү: | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.1.1 | Сәнәгый агынты суларны агызу | | | | | | | 1,05 | 1,05 | 1,05 | 1,05 | 1,05 | 1,05 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.11.2017 № 10-30/кс карарына 2 нче кушымта «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 10-167/кс карары редакциясендә)

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Яр Чаллы ҖЭҮ филиалы өчен 2018-2020 елларга салкын суны транспортлауга һәм су бүлүгә тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Яр Чаллы ҖЭҮ филиалы | | | | | | |
| 1.1.1 | Салкын суны транспортлауга | 2018 | 5,18 | 1 | – | – | - |
| | | 2019 | 5,36 | 1 | – | – | - |
| | | 2020 | 5,49 | 1 | – | – | - |
| 1.1.2 | Агынты суларны транспортлау | 2018 | 336,93 | 1 | – | – | - |
| | | 2019 | 348,91 | 1 | – | – | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 | 357,16 | 1 | – | – | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге